КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 8 декабрь г.Казань № 1108

«Бөгелмә медицина училищесы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенә Вязьмин Анатолий Павлович исемен бирү турында

РСФСР мәктәбенең атказанган укытучысы, Татарстан АССРның атказанган табибы, Бөгелмә медицина училищесының элеккеге директоры Вязьмин Анатолий Павлович истәлеген мәңгеләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Бөгелмә медицина училищесы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенә А.П.Вязьмин исемен бирү турындагы тәкъдимен кабул итәргә һәм алга таба да аны «А.П.Вязьмин исемендәге Бөгелмә медицина училищесы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе дип атарга.

2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына 30 көн эчендә «Бөгелмә медицина училищесы»дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе уставына тиешле үзгәрешләр кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин